| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 14 ноябренә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

- Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту.
- Куакбаш авылында елның теләсә кайсы вакытында янгын сүндерү автомобильләре су алу өчен, зурлыгы 12*12 метрдан ким булмаган каты өслекле керү мәйданчыклары урнаштыру.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Куакбаш авылы - җирле үзидарә бинасы, К. Маркс урамы, 15, Сходнево-Черталы авылында – клуб бинасында Свобода урамы, 5 Б, Чүте авылы – клуб бинасында, Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р. Әхмәтҗанова